**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӘВЕШ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

3 сентябрь, 2019 ел №157

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте белән идарә итү, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында "2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы," Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 мартындагы 5 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте белән идарә итү, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлектәге 5.4 пунктның 15 пунктчасында "документациясен раслау" сүзләреннән соң "җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең планын раслау" сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Дәвеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Дәвеш авыл җирлеге башлыгы Т.Т. Хөсәенов**